КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, ноябрь г.Казань № 1391

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләре кешеләр иминлегенә, аларның сәламәтлеген һәм җәмгыятьнең тормыш өчен әһәмиятле мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә бәйле оешмаларның, шәхси эшмәкәрләрнең хезмәткәрләре забастовка үткәрелгән чорда Татарстан Республикасы территориясендә башкара торган кирәкле эшләр (хезмәт күрсәтүләр) минимумы исемлеген раслау турында» 2009 ел, 10 март, 141 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләре кешеләр иминлегенә, аларның сәламәтлеген һәм җәмгыятьнең тормыш өчен әһәмиятле мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә бәйле оешмаларның, шәхси эшмәкәрләрнең хезмәткәрләре забастовка үткәрелгән чорда Татарстан Республикасы территориясендә башкара торган кирәкле эшләр (хезмәт күрсәтүләр) минимумы исемлеген раслау турында» 2009 ел, 10 март, 141 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 гыйнвар, 67 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Һөнәри берлекләр оешмаларының территориаль берләшмәләре белән килештереп, икътисадның тиешле тармакларында (ярдәмче тармакларында) эшчәнлек белән идарә итү, аны координацияләү һәм җайга салу йөкләнгән республика башкарма хакимият органнары тарафыннан икътисадның тиешле тармакларында

(ярдәмче тармакларында) әлеге Исемлекне куллану тәртибе эшләнә һәм раслана.»;

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин